Республика Татарстан
Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

ул.Центральная, д. 30, пос.Победа
Азнакаевский район, 423312

Үзәк урамы, 29 нче йорт, Җиңү
бистәсе, Азнакай районы, 423312

Тел. (факс) 8(85592) 42-1-38; e-mail: Vahit.Azn@tatar.ru
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2020 ел. №3

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Чәкән торак пункты, Базар урамы, 2 адресы буенча урнашкан Чәкән торак йорты мәдәният йорты бинасында 2020 елнын 26 ноябрендә 14.00 сәгать 00 минутта Чәкән авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында 2021 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, кендезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Чәкән торак пунктының Яңа урам буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон еслекле юлларның чокырларын ямау);

-Чәкән торак пунктында православие һәм мөселман зиратларында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләп алу очен материаллар сатып алу, коймалар

ясау һәм урнаштыру,  контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез, киртәләр урнаштыру);

- Чәкән торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен отвал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Чәкән торак пунктында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, лампаларны, яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган һәйкәлне реконструкцияләү (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Чәкән авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара елкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны,  кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru)  урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай районы Вахитов
авыл җирлеге башлыгы И.Б. Бохарова